ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Иске Барыш авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның 24 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Иске Барыш авылында гражданнар җыены:

1.2024 елда Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 650 (алты йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә, Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәмәгән кешеләрдән һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (шул исәптән урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру)ремонтлау;

2) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, фронталь йөк төягечле һәм бульдозерлы отваллы трактор өчен запас частьләр сатып алу);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән җәйге вакытта территорияне урып-җыю, ягулык-майлау материаллары, КРН-2.1 б ротацияле косилкалы трактор өчен запас частьләр сатып алу, трактор өчен прицеплы арба сатып алу).

3.Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Иске Барыш авылы, Үзәк урам, 15 йорт, авыл клубы бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Иске Барыш авыл
җирлеге башлыгы: И. Р. Җиһаншин